**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Туйкә авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Туйкә авылы № 115-66 «03»сентябрь 2024 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге Советының 2011 елның 01 ноябрендагы 21 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлегенең муниципаль милкендәге мөлкәтне арендага бирү тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәреш һәм өстәмә кертү хакында (09.10.2018 №116-54 карар редакциясендә)

«Электр энергетикасы турында»гы Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»гы 2024 елның 13 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Туйкә авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. 3.1 пунктының тугызынчы абзацына «Җылылык белән тәэмин итү турында»гы 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә җылылык белән тәэмин итүнең бәя зоналарында бердәм җылылык белән тәэмин итү оешмасы статусы бирелгән затка «Электр энергетикасы турында»гы 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә система барлыкка китерүче территориаль челтәр оешмасы статусы бирелгән затка» сүзләрен өстәп, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге Советының 2011 елның 01 ноябрендагы 21 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлегенең муниципаль милкендәге мөлкәтне арендага бирү тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет, салымнар, финанс һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Р.Р. Закирова